| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 17 декабре Кукмара ш. № 92

Кукмара муниципаль районының 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджеты турында

Муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан тәкъдим ителгән 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджетын карап, Кукмара муниципаль районы Советы карар бирде:

**1 статья**

1. 2022 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Кукмара муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 1 573 771 420,00 сум;

2) Кукмара муниципаль районы бюджетының гомуми чыгымнары күләме 1 573 771 420,00 сум;

3) Кукмара муниципаль районы бюджеты дефициты (профициты) 0 сум күләмендә.

2. 2023 елга һәм 2024 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Кукмара муниципаль районы бюджеты керемнәренең 2023 елга фаразлана торган гомуми күләмен 1 574 018 620,00 сум һәм 2024 елга 1 576 115 820,00 сум күләмендә;

2) Кукмара муниципаль районы бюджетының 2023 елга гомуми чыгымнары күләме 1 574 018 620,00 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 14 264 100 сум һәм 2024 елга 1 576 115 820,00 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 30 333 000 сум;

3) Кукмара муниципаль районының 2023 елга бюджет дефициты (профициты) 0 сум, 2024 елга 0 сум күләмендә.

3. Кукмара муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын түбәндәгечә билгеләргә:

2022 елга әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

2023 елга һәм 2024 елга әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә.

**2 статья**

1. 2023 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

Кукмара муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

2. 2024 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

Кукмара муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

3. 2025 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

Кукмара муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

**3 статья**

Кукмара муниципаль районы бюджетында 2022 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының фаразланыла торган керем күләмен әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

Кукмара муниципаль районы Юл фондының 2022 елга бюджет ассигнованиеләре күләмен 30 400 мең сум күләмендә расларга, 2023 елга 31 700 мең сум күләмендә, 2024 елга 31 800 мең сум күләмендә расларга һәм аларны 2022, 2023 һәм 2024 елларга Кукмара муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын тормышка ашыруга юнәлдерергә.

**5 статья**

1. Бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне расларга:

2022 елга әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә;

2023 һәм 2024 елларга әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә.

2. Кукмара муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

2022 елга әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә;

2023 һәм 2024 елларга әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә;

3. гавами норматив йөкләмәләрне үтәү өчен бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 9 нчы кушымта нигезендә 2022 елга 1 976 000,00 сум, 10 нчы кушымта нигезендә 2023 елга 1 976 000,00 сум һәм 2024 елга 1 976 000,00 сум күләмендә расларга.

**6 статья**

1. Кукмара муниципаль районы бюджетына Кукмара шәһәре бюджетыннан муниципаль торак фондын капиталь ремонтлау буенча төзелгән килешү нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен башка бюджетара трансфертларның күләмен 2022

елга 4 388 000 сум, 2023 елга 4 388 000 сум, 2024 елга 4 388 000 сум күләмендә исәпкә алырга.

Кукмара шәһәренә бюджетта югарыда күрсәтелгән максатларга тиешле субсидияләрне күздә тотарга тәкъдим итәргә.

2. Кукмара муниципаль районы бюджетына җирлек бюджетларыннан финанс контроленә төзелгән килешү нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен башка бюджетара трансфертларны 11 нче кушымта нигезендә 2022 елга 609 000 сум күләмендә, 2023 елга 609 000 сум күләмендә, 2024 елга 609 000 сум күләмендәисәпкә алырга.

Кукмара муниципаль районы җирлекләренә бюджетларда югарыда күрсәтелгән максатларга тиешле субсидияләрне күздә тотарга тәкъдим итәргә.

3. Кукмара муниципаль районы бюджетына төзелгән килешү нигезендә, җир биләмәләреннән файдалану һәм җирлекләр төзү буенча расланган кагыйдәләр булганда, дәүләт милке чикләнмәгән һәм җирлекләр территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларыннан башка бюджетара трансфертлар күләмен 12 нче кушымта нигезендә 2022 елга 100 000 сум күләмендә, 2023 елга – 100 000 сум, 2024 елга – 100 000 сум күләмендә исәпкә алырга.

Кукмара муниципаль районы җирлекләренә бюджетларда югарыда күрсәтелгән максатларга тиешле субсидияләрне күздә тотарга тәкъдим итәргә.

**7 статья**

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә җирлекләр бюджетларына дотацияләр күләмен расларга:

әлеге карарның 13 нче кушымтасы нигезендә бүлеп, 2022 елга 34 481 000 сум күләмендә,

әлеге карарның 14 нче кушымтасы нигезендә бүлеп, 2023 елга 33 627 900 сум күләмендә,

әлеге карарның 15 нче кушымтасы нигезендә бүлеп, 2024 елга 32 973 200 сум күләмендә.

**8 статья**

Кукмара муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирлекләр бюджетларыннан алына торган бюджетара трансфертларның күләмен түбәндәгечә исәпкә алырга:

әлеге карарның 16 нчы кушымтасы нигезендә бүлеп, 2022 елга 1 063 323 720,00 сум күләмендә,

әлеге карарның 17 нче кушымтасы нигезендә бүлеп, 2023 елга 1 028 383 320,00 сум күләмендә,

әлеге карарның 17 нче кушымтасы нигезендә бүлеп, 2024 елга 993 303 320,00 сум күләмендә.

**9 статья**

1. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе

учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләре чыгымнар артуга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарларны кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

**10 статья**

Кукмара муниципаль районының ___________ авыл җирлеге бюджетыннан авыл җирлеге исеменнән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар төзелгән өчен файдаланылмаган, әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2021 елда түләнергә тиешле бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә акча калдыклары, ________________ авыл җирлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, 2022 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**11 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Кукмара муниципаль районы буенча территориаль бүлеге килешү нигезендә һәм түләүсез нигездә Кукмара муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**12 статья**

Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**13 статья**

Әлеге карарны «Хезмәт даны» район газетасында бастырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев